## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге Яңа Әхмәт торак пунктында
2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

21 ноябрь 2025 ел № 2

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында халык җыены

**карары:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган зат , I һәм II группа инвалидларыннан, ел дәвамында җирлек территориясендә яшәмәүче гражданнардан (студентлар; РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче затлар, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар; хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзалары (социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр, янгыннан зыян күрүчеләрдән) тыш, 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Яңа Әхмәт торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

2) Яңа Әхмәт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау;

3 )Яңа Әхмәт торак пунктындагы традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Советы Башлыгы Ф.М.Хөснуллин